| ГЛАВА<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь, 2024 ел Кошман ав. № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Урсак урман хуҗалыгы посёлогында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 28 ноябрена 09 сәг 00 минутка Урсак урманчылыгы посёлогы, Камал ур, 17 йорт адресы буенча урнашкан Урсак урманчылыгы конторасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Урсак урман хуҗалыгы посёлогында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. .Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге территориясенә кергән Урсак урман хуҗалыгы посёлогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина